МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

№3 (57) Декабрь, 2023 нче ел

**Бу санда**

*Гимназия сулышы* 2

*Кыш бабайдан нинди бүләк сорар идегез?* 3

*Ап-ак кышка ияреп, зур бәйрәм килә безгә* 3

*Могҗиза көткәндә* 4

*Аждаһа әйтсә, хак әйтә...* 4

***Яңа 2024 ел мөбәрәк булсын!!!***




## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Яңа елга аяк басканда!




***Хөрмәтле хезмәттәшләрем, укучылар!***

Сезне чын күңелдән якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм! Эшегездә, укуыгызда, тормышыгызда зур уңышлар юлдаш булсын!

Бик тиздән, 2024 ел җитүен хәбәр итеп, Яңа ел сәгате сугачак. Һәм без тарихыбызның тагын бер битен ябып, яңа сәхифәсен ачачакбыз.

Узып баручы елны озатканда хәтердә уелып калган иң якты, иң шатлыклы вакыйгаларны искә алабыз. Ә андый вакыйгалар күп булды: укучыбыз Исмәгыйлова Лиана ике фәнне Бердәм дәүләт имтиханнарында 100әр баллга тапшырды, гимназиянең 20 еллыгын билгеләп үттек...

Ул җитди эшләргә, мавыктыргыч вакыйгаларга бай һәм мөһим социаль проектларның гамәлгә ашыру елы булды. Болар барысы да – безнең уртак тырыш хезмәтебез нәтиҗәсе. Мин һәрберегезгә рәхмәтлемен.

Чын күңелдән сезгә ныклы сәламәтлек, үз көчегезгә ышану, тыныч күк йөзе, бәхет һәм иминлек телим!

***Мөслим гимназиясе директоры Азат Фәрит улы Мирзаянов***

### «Ел укытучысы — 2024»



«Ел укытучысы» Бөтенроссия бәйгесенең муниципаль этабы нәтиҗәләре билгеле булды.

Гимназиянең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Фәхретдинова Ләйсән Әхмәтгаян кызы** “Ел укытучысы - 2024” республика конкурсының муниципаль этабында икенче урынга лаек булды, физика укытучысы **Әгләмов Ринат Булат улы** “Педагогик дебют” номинациясендә җиңүче буларак билгеләнде. Аларны ихластан котлыйбыз, киләчәктә дә уңышлар телибез!

### Олимпиада нәтиҗәләре




9 ноябрьдән башланган Татарстанда мәктәп укучыларының республика һәм Бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль этабы тәгәлләнде.

Агымдагы уку елында да укучыларыбызның нәтиҗәләре куандыра. Гимназиялеләр **40 җиңү, 201 призлы** урын яулады.

Укучыларыбызга ирешелгән нәтиҗәдә тукталып калмауларын, тагын да күбрәк белүләрен телибез.

Кадерле укучыларыбыз, күзләрегездә һәрвакыт очкын янсын, мөмкинлекләр ачылып торсын, уңыш һәрвакыт сезнең якта булсын!

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## Гимназия республика бәйгесендә җиңү яулады



Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Мәктәп экопатруле» республика конкурсына йомгак ясалды. Безнең гимназия "Иң актив мәктәп" номинациясендә икенче урынга лаек булды. Бу безнең укучыларның һәм аларның ата-аналарының уртак җиңүе. Котлыйбыз!

## Йомгаклау иншасы

Бердәм дәүләт имтиханы – мәктәп тәмамлаучылар өчен дәүләт аттестациясенең төп формасы. Аның нәтиҗәләре югары һәм урта махсус уку йортларына укырга керү имтиханы да булып тора.

6 декабрьдә Россия мәктәпләренең унберенче сыйныф укучылары бердәм дәүләт имтиханнарына кертү ролен үтәүче инша язды.

## «Ел укучысы» җиңүчеләре



Дүртенче сыйныф укучылары арасында, 27 нче декабрьдә, гимназия базасында "Ел укучысы - 2024" муниципаль конкурсының зона туры үтте.

Анда гимназиябезнең 4 нче сыйныф укучылары да катнашып, үз осталыкларын күрсәттеләр. Нәтиҗәләр түбәндәгечә: 1 нче урынга 4 нче в сыйныф укучысы Гәрәев Әмин (укытучысы Гәлимарданова З.Д.), 2 урынга 4 нче а сыйныфыннан Фазлиева София (укытучысы Гомәрова А.Р.), 3 нче урынга 4 нче б сыйныф укучылары Шәймурзин Алмаз белән Сәләхов Ранель (укытучылары Исмәгыйлова Г.Ф.) лаек булдылар.

*СПОРТ. СПОРТ. СПОРТ.*

## Илина мактаулы исемгә лаек булды



Гимназиябезнең 11 нче сыйныф укучысы Бариева Илина «Россия спорт мастеры» исеменә лаек булды! Илинабыз озак еллар спортның армреслинг төре белән шөгыльләнә. Илинаны әлеге зур җиңүе белән котлыйбыз!

## "КЭС-Баскет" уеннары




Азнакай шәһәрендә "КЭС-Баскет" мәктәп баскетбол лигасының Бөтенроссия чемпионатының дивизион этабы узды.

Гимназиянең баскетбол командасы егетләре өченче урынны яуладылар. Команда баскетбол формалары алу өчен сертификат белән бүләкләнде! Команданың тренерлары: Дамир Шәйхетдинов, Динар Булатов. Егетләребезне котлыйбыз! Киләчәктә дә уңышларга ирешүләрен телибез.

## Хәйрия ярминкәләре

Гимназиядә ел саен традицион рәвештә уза торган матур гадәт бар: инвалидлар декадасы кысаларында хәйрия ярминкәсе уза. Быел да ярминкә гөрләп үтте. Ул базар сыман гөж килеп торды. Укучылар ни генә сатмадылар: өйдә пешкән тәм-томнар, камыр ризыклары, бәйләнгән мунчала, суыра торган конфетлар, ассортимент шул кадәр бай иде.

Ярминкәдән кергән акча физик мөмкинлеге чикләнгән балалар тәрбияләүче гаиләләргә бирелде.




*Сәламәтлек рубрикасы*

## Сәламәт булыйк!



Грипп – куркыныч чир. Ул вирус аша йога. Вирусларны ыклап хәлсезлек тоелмаган, чирне җиңелчә үткәреп йөргән авырулар тарата. Грипп белән чирләүче әйләнә-тирәдәгеләрне сөйләшкәндә, йөткергәндә, төчкергәндә һавага төкерек тамчылары белән вирус таратып зарарлый. Грипп авыруын йоктырмас өчен, иң беренче чиратта, иммун системагызны ныгыту кирәк. Витаминнар күбрәк ашарга. Шулай ук салкында юка киенеп йөрүдән, туңудан сакланырга. Салкын тидермәскә. Авыру янына битлек киеп керергә. Авырып китүчегә күп итеп сыеклык эчертергә, ютәлләгәндә һәм төчкергәндә авыз-борыныгызны бер тапкыр кулланучы кулъяулыклар белән капларга, аннары аларны юк итегәргә.

Онытмагыз, инфекцияне кисәтү өчен табыныгыз бал, карлыган вареньесы, сарымсак, суган, лимон, җиләк-җимеш, тозлы кәбестә кебек ризыкларга бай булырга тиеш.

## СПИДка каршы торыйк!

Ел саен 1 декабрь көнне СПИД ка каршы Бөтендөнья көрәш көне билгеләп үтелә. Ул планета төбәкләре буенча таралуын дәвам итүче ВИЧ-инфекциягә каршы көрәшне ныгытуга хезмәт итә. Эпидемия башыннан 30 ел эчендә СПИД 25 миллионнан артык гомерне алып киткән, 60 миллионнан артык кеше ВИЧ белән йогышланган, 16 миллион бала ата-анасыз калган. Әлегә кадәр бу вирусны көн саен 7 меңнән артык кеше йоктыра.

## КЫШ БАБАЙДАН НИНДИ БҮЛӘК СОРАР ИДЕГЕЗ?

***Яңа елга санаулы көннәр генә калып калып бара. Аны һәркем, аеруча балалар түземсезлек белән көтә. Шулай булмый мөмкин түгел. Ул бит могҗизалар, кызыклы, мавыктыргыч, тәмле, иң мөһиме - көтелгән бүләкләр бәйрәме.***

***Без дә гимназия укучыларына шушы сорау белән мөрәҗәгать иттек. Нинди җаваплар ишеттек соң...? Менә алар:***

Мин Кыш бабайдан чаңгылар сорар идем. Минем алар юк, шул чаңгыларны тагып, кышкы урманга хозурланып кайтасым килә. Кыш бабай чаңгылар алып килер дип көтәм (Камил);



Яңа ел дигәч шунда ук исемә бүләкләр бирү традициясе төшә. Ә могҗизаларны Кыш бабай тудыра кебек тоела. Әти-әнием, туганнарым, якыннарым янәшәмдә булу зур бүләк. Барлык кешеләргә дә сәламәтлек, ил-көннәребезгә тынычлык алып кил Кыш бабай! (Айназ);

Мин Кыш бабайдан әти-әнинең бәхетле, сәламәт булуын, үземә, БДИны уңышлы тапшырып, теләгән уку йортына керүемне сорар идем (Илназ);

Кыш бабай Парижга барырга ярдәм итсен иде (Зәринә);

Үсә барган саен, Кыш бабайга ышанмыйсың да кебек. Шуңа карамастан, мин аннан барлык кешеләргә бәхет, илебезгә тынычлык алып килсен дип сорар идем (Камилла);

Кыш бабай матур алкалар алып килсен иде (Адилә);

Миңа Кыш бабай күп акча алып килсен иде (Зәринә).

## АП-АК КЫШКА ИЯРЕП, ЗУР БӘЙРӘМ КИЛӘ БЕЗГӘ

### Кышның энҗе-мәрҗәннәре

Туган ягыма кыш килде. Бар дөньяны ап-ак кар каплады. Салкын һава битләрне өшетә. Энҗе кар бөртекләре йомшак кына керфек очларына куна да, минем сулышымнан эреп юкка чыга. Ә менә агачлар энҗе бөртекләрдән мамык шәл бәйләп бөркәнгәннәр. Шәлләренә нәфис бизәк булып кызылтүшләр тезелгән.

Бу сихри җиһанга кояш үзенә бертөрле серлелек өсти. Җир өслегендә ялтырап яткан энҗе-мәрҗәннәр күз явын алырлык! Кыш бик матур ел фасылы шул!

***Бәдертдинова Зәринә,***
***6 нчы а сыйныфы укучысы***

### Кыш бик матур ул!

Ап-ак карлар яудырып, кабат Мөслимебезгә кыш килде. Көннәр бик нык суытты, салкын җилләр исә башлады. Кайбер көннәрдә матур итеп кар ява. Ул көнне мин өйдә утырмыйм, тизрәк тышка чыгам. Кар бөртекләре минем өстемә, битемә куналар. Балалар урамда рәхәтләнеп чанада, чаңгыда шуалар, Кар бабай ясыйлар.

Кар тирә-юньдәге агачларны да суыктан саклый, үзенең ак юрганы белән төрә. Кыш бик матур ул!

***Галиева Иркә,***
***6 нчы а сыйныфы укучысы***

### Мөслимемә кыш килде

Минем туган ягым Мөслимгә дә кыш килде. Җир өсте ак кар белән капланды. Көннәр салкынайды. Агачлар әллә кайчан алтын яфракларын койды. Күк йөзен авыр соры болытлар каплады. Ул болытлардан көн саен җир өстенә ап-ак мамык кебек кар төшә. Кайчагында кышның саран гына саргылт кояшы да күренгәли.


Кыш - күпме шатлык алып килүче ел фасылы ул! Без тауда чана, чаңгы шуабыз, Кар бабай ясыйбыз. Әле тиздән Яңа ел киләчәк! Безгә Кыш бабай кучтәнәчләр өләшәчәк. Мин кышны бик яратам!

***Хасанова Асылъяр,***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

### Кыш бабай булам

Үскәч кем буласың диләр? Мин үскәч Кыш бабай булам. Бөтен балага да бүләк алып киләм. Мин урманда бер бик матур өйдә яшиячәкмен. Минем белән бергә биш сибирский хаски һәм алты болан яшәячәк. Мин аларны бик әйбәтләп ашатачакмын һәм ярататачакмын. Ел буена миңа төрле ил балаларыннан бик күп хатлар киләчәк. Минем янымда үземнең шәхси тәрҗемәчем дә булачак. Ул миңа хатларны тәрҗемә итеп торачак, ә мин балаларга алар сораган бүләкләрне әзерләячәкмен. Ул бүләкләрне ясашырга мин тагын берничә ярдәмче тотачакмын. Без ул бүләкләрне боланнарга утырып, төрле илләрдә яшәүче балаларга таратачакбыз.

***Муллагалиев Илдан,***
***3 нче в сыйныфы укучысы***



*Яңа ел бит ул могҗиза,*
*Яңа ел - тылсым.*
*Яңа елда һәр кылган эш*
*бәхеткә булсын!*
*Карлар белән бергә*
*җанга ак өмет иңсен.*

## МОГҖИЗА КӨТКӘНДӘ

***Хөрмәтле гимназиялеләр!***

Бәхет-шатлыклары, борчу-мәшәкатьләре, хезмәт уңышлары, вакыт-вакыт киеренкелеге, искә ала торган вакыйгалары, куанычлары, күңел дәртен биреп башкарган эшләре белән тагын бер ел тарих булып калачак. Күңелләрдә әле узып баручы елның якты хатирәләре, онытылмас җылы истәлекләре, табышлар, югалтулар...

Киләсе елның 365 көне бары тик бәхет-шатлык кына китерсен. Сезнең барыгызны да ихлас күңелдән 2024 нче ел белән котлыйбыз. Бу ел барыбызга да иминлек, саулык-сәламәтлек, куанычлар, бәрәкәт алып килсен.

*Эшләребез уң булсын,*
*Тик шатлыклы минутлардан*
*Безнең гомерләр торсын!*
*Яңа ел котлы булсын!*

***«Тылсым+» газетасы редколлегиясе***







*Яңа ел бит ул могҗиза,*
*Яңа ел - тылсым.*
*Яңа елда һәр кылган эш бәхеткә булсын!*
*Карлар белән бергә җанга ак өмет иңсен.*

## АҖДАҺА ӘЙТСӘ, ХАК ӘЙТӘ...




Тәрбияле, киң күңелле **ҮЛЧӘҮ**гә бу ел бик күп үзгәрешләр алып килер. Яхшы укырга, сәләтләреңне ачарга тырыш. Спорт белән дуслашу да файдага булыр.

***

Төгәл, дан яратучы **ЧАЯН** Яңа елга ышанычлы адымнар белән атлый. Якыннарыңа синең игътибарың кирәк. Укуда яңа проект-лар белән аерылып тора ала-сың.

***

Шаян, җитез **УКЧЫ** өчен яңа дуслар табу елы. Шулвакыт укуда һәм иҗатта уңышка ирешерсең. Уңай үзгәрешләр озак көттермәс.

***

Тәвәккәл, төгәл **КӘҖӘМӨГЕЗ** өчен тыныч ел. Максатларыңны дөрес билгеләсәң, төрле өлкәдә уңышка ирешә аласың.

Иң мөһиме – үз-үзеңә ышану.

***

Яңалык яратучы **СУКОЯР** сыйныфташлары белән дуслыгын ныгытыр. Тирә-юньдәгеләргә мәрхәмәтле бул. Үзеңне яңа юнәлешләрдә сынап кара.

***

Серле **БАЛЫК**лар өчен якты һәм күңелле ел килә. Яңа танышулар, бәйрәмнәр күп булыр. Шул ук вакытта уку турында да онытма!

***

Тиктормас һәм кызыксынучан **КУЧКАР** өчен укуда, иҗат һәм спортта уңышлы ел килә. Һәрвакыт хәрәкәттә булырга тырыш! Өй эшләрен вакытында эшләп йөр.

***

Сабыр һәм туры сүзле **ҮГЕЗБОЗАУ** күп игътибарын укуга бирәчәк. Сыйныфта староста урынын тәкъдим итсәләр, баш тартма. Башкаларга үрнәк була аласың.

***

Мөстәкыйль һәм үзгәрүчән холыклы **ИГЕЗӘК**ләрне могҗизаларга бай ел көтә. Кызыклы идеяләрең булса, аларны тормышка ашырырга ашык! Уңышка ирешерсең.

***

Хисле һәм сакчыл **КЫСЛА** күп эшләрендә дөрес карарлар кабул итәр. Якыннарыңа ярдәмчел бул. Укуга игътибарыңны арттыр. Нәтиҗә сөендерер.

***

Көчле, һәрчак алга омтылган **АРЫСЛАН**га Аҗдаһа елында тынычлык кирәк булыр. Елларда китап укырга, музей һәм театрларга барырга мөмкин.

***

Эш сөючән, максатчан **КЫЗ** ел буе күңелле вакыйгаларга сөенер. Үзеңнең иң яхшы сыйфатларыңны күрсәтергә курыкма. Кыю һәм тәвәккәл бул!


ТЫЛСЫМ+
Декабрь, 2023 нче ел
№3 (57)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Мингазова Камилә
**Корректорлар:** Мингазова Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Замалова Зәринә
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж**: 100